КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 сентябрь г.Казань № 716

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан

Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 август, 746 нчы, 2022 ел, 29 декабь, 1440 нче, 2023 ел, 4 февраль, 99 нчы, 2024 ел, 4 март, 120 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 пунктта:

егерме икенче абзацта «1,605» саннарын «1,835» саннарына алмаштырырга;

егерме сигезенче абзацта «1,485» саннарын «1,715» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин